МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.11.2019 г.Казань № 1018

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 19 декабрендә 6079 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елныж 20 ноябрендәге 1064 номерлы боерыгы белән расланган Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 20 ноябрендәге 1064 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 7 маендагы 328 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
14.11.2019 № 1018 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 20 ноябрендәге 1064 номерлы боерыгы белән расланган Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.3 пунктта:

беренче абзацта һәм алга таба Регламент тексты буенча «дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларында һәм саннарда кулланып, тиешле килешләрдә һәм саннарда «гариза бирүче» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Халыкның мәшгульлек үзәге урнашкан урын, аның эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы порталында урнаштырылган.

Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.»;

1.7 пунктта:

1 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) халыкның мәшгульлек үзәгендә гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.6, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;

4 пунктчаны көчен югалткан дип танырга;

1.8 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.8. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләр нигезендә күрсәтелә:

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 1, 3 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы («Ведомости Съезда народных депутатов РСФСР и Верховного Совета РСФСР», 1991, № 18, 565 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – Халык мәшгульлеге турында закон);

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 48, 4563 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, №30, 3032 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31, 3451 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, №15, 2036 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, №19, 2338 статья) (алга таба – 601 номерлы указ);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы турында» 2010 елның 8 сентябрендәге 697 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №38, 4823 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр һәм федераль башкарма хакимият органнары, бюджетка карамаган дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары арасында үзара хезмәттәшлек итү турында» 2011 елның 27 сентябрендәге 797 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, №40, 5559 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Туры килә торган эш эзләү максатларында гражданнарны теркәүгә алу, эшсез гражданнарны теркәүгә алу тәртибе һәм туры килә торган эш эзләүгә карата таләпләр турында» 2012 елның 07 сентябрендәге 891 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, №38, 5103 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 2012 елның 7 сентябрендәге 981 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Инвалидларның хокуклары турында конвенция буенча Россия Федерациясе йөкләмәләрен үтәү өчен күрелә торган чаралар турында доклад әзерләү тәртибе турында» 2015 елның 11 июнендәге 585 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, №25, 3666 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерияләрен раслау турында» 2016 елның 27 октябрендәге 1096 номерлы карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы, (www.pravo.gov.ru), 2016, 1 ноябрь, басылып чыгу номеры: 0001201611010013, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мөмкинлекле тирәлек» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 29 мартындагы 363 номерлы карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы, (www.pravo.gov.ru), 2019, 8 апрель, басылып чыгу номеры: 0001201904080016);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларны, сәламәтлеге буенча мөмкинлеге чикләнгән затларны һәм балигълык яшенә җитмәгәннәрне озата йөрүче» профессиональ стандартын раслау турында» 2015 елның 16 ноябрендәге 871н номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 18 декабрь, басылып чыгу номеры: 0001201512180009, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Мәшгульлек органнары һәм медик-социаль экспертиза буенча федераль учреждениеләр арасында белешмәләр алмашу тәртибен, формасын һәм срокларын раслау турында» 2015 елның 16 ноябрендәге 872н номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 14 декабрь, басылып чыгу номеры: 0001201512140027, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 2015 елның 16 ноябрендәге 872н номерлы боерык);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Медик-социаль экспертиза буенча дәүләт учреждениеләреннән бирелә торган инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм аларның формаларын раслау турында» 2017 елның 13 июнендәге 486н номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 1 август, басылып чыгу номеры: 001201708010058, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкны эшкә урнаштыруга булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән

файдаланучының шәхси эш бланклары формаларын раслау турында» 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүмат тупланган рәсми интернет-портал (www.pravo.gov.ru), 2019, 19 март, басылып чыгу номеры: 0001201903190024) (алга таба – 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр сайлауда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәтенең федераль дәүләт стандартын раслау турында» 2012 елның 13 ноябрендәге 524н номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр сайлауда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәтенең федераль дәүләт стандарты (Российская газета, 2013, 30 гыйнвар, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 2012 елның 13 ноябрендәге 524н номерлы Федераль стандарт);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 3 августындагы 518н номерлы боерыгы белән расланган Инвалидларга эшкә урнашуда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәтенең федераль дәүләт стандарты (Хокукый мәгълүматның рәсми порталы (www.pravo.gov.ru), 2018, 22 август, басылып чыгу номеры: 0001201808220025) (алга таба – 518н номерлы федераль стандарт);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 33, 1178 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары белән расланган Тәртип).»;

1.9 пунктның өченче абзацында «арифметик хата» сүзләреннән соң «яки шуңа охшаш хата» сүзләрен өстәргә;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәтне яки |
|---|---|---|

| күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы | | таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Инвалидларга эшкә урнашуда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру | Халык мәшгульлеге турында законның $7^{1-1}$ статьясының 1 пунктындагы 8 пунктчасы |
| 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждение) атамасы | Татарстан Республикасы Халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениесе (алга таба – халыкның мәшгульлек үзәге).<br>Халыкның мәшгульлек үзәге Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлеге территориясендә дәүләт хезмәте күрсәтелүен гамәлгә ашыра. | Халык мәшгульлеге турында законның $7^{1-1}$ статьясының 1 пунктындагы 8 пунктчасы |
| | Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан шартнамә нигезендә җәлеп ителә торган, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тиешле хезмәтләрне күрсәтүгә хокуклы булган дәүләткә карамаган оешмалар, шул исәптән ихтыяри (волонтерлык) оешмалары тарафыннан озата йөрүне гамәлгә ашыру рөхсәт ителә | 518н номерлы федераль стандартның 11 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булып инвалидка инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә (алга таба – бәяләмә) бирү тора.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе инвалидның ихтыяры буенча кәгазьдәге документ формасында да, шулай ук әлеге Регламент нигезендә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында да бирелергә мөмкин. | 518н номерлы федераль стандартның 16 пункты, 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 25 нче кушымта |

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь мөмкин булган вакыты - 60 минут.<br>Инвалид белән халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итү датасын һәм вакытын килештерү, Интернет челтәрен дә кертеп, телефоннан яки электрон элемтәдән, шулай ук почта элемтәсеннән файдаланып, гаризаны теркәгән көннән соң килгән эш көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла<br><br>Инвалид КФҮ мөрәҗәгать иткән очракта, КФҮ белән халыкның мәшгульлек үзәге арасында төзелгән хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән срокларда, ләкин гаризаны теркәгән көннән башлап киләсе эш көненнән соңга калмыйча, гаризаның халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшырылуы тәэмин ителә.<br>МСЭ тарафыннан бирелгән ТАХП шәхси ихтыяр белән тапшырылмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь мөмкин булган вакыты гариза бирүче гариза тапшырган датадан башлап 7 эш көненнән артык булырга тиеш түгел.<br>Инвалидка эшкә урнашуда булышлык күрсәткәндә озата йөрү турында шартнамәгә (алга таба – шартнамә) халыкның мәшгульлек үзәге һәм озата йөрү рәвешендә инвалидка хосусый ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыручы, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тиешле хезмәтләрне күрсәтергә хокуклы булган дәүләткә карамаган оешма, шул исәптән ихтыяри (волонтерлык) оешма (алга таба – оешма) тарафыннан имза кую срогы озата йөрүне гамәлгә ашырачак оешма билгеләнгән датадан башлап 2 эш көненнән артык булырга тиеш түгел.<br>Инвалидка бәяләмә бирү срогы | 518н номерлы федераль стандартның 7 пункты<br><br>518н номерлы федераль стандартның 8 пунктының 2 абз.<br><br>518н номерлы федераль стандартның 9 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | халыкның мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтү бурычы йөкләнгән белгече (алга таба – халыкның мәшгульлек үзәге белгече) аны төзегән вакыттан башлап 10 минуттан артып китәргә тиеш түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаның КФҮ булган вакыты (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны КФҮ аша тапшырган очракта), шулай ук оешма тарафыннан шартнамәгә кул кую вакыты дәүләт хезмәте күрсәтү срогына керми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору Россия Федерациясе законнарында каралмаган | |
| 2.5. Закон яисә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен зарури булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | Дәүләт хезмәтен алу өчен дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза).<br>Дәүләт хезмәте алу буенча гариза кәгазен гражданин халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин.<br>Бланкның электрон формасы халыкның мәшгульлек үзәге рәсми сайтында, Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган.<br>Гаризада түбәндәгеләр күрсәтелгән булырга тиеш:<br>инвалидның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта);<br>мөрәҗәгать итү датасы.<br>Гариза инвалидның шәхси яки 63-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә гади электрон имзасы белән таныклана.<br>Инвалид өчен гариза бирү ысулын сайлау мөмкинлеге тудырыла.<br>Гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә яки КФҮ, почта элемтәсе ярдәмендә, факсимиль | 518н номерлы федераль стандартның 5 ункты, 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 13 нче кушымта<br><br>518н номерлы федераль стандартның 5 пункты, 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 13 нче кушымта<br>63-ФЗ номерлы федераль закон, 210-ФЗ номерлы федераль закон, 518н номерлы федераль |

| | | |
|---|---|---|
| | элемтә чараларыннан файдаланып яки гади электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында, шул исәптән халыкның мәшгульлек үзәгенең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан, Бердәм порталдан яки «Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында «шәхси кабинет» аша (алга таба - «Инвалидларның федераль реестры» системасында «шәхси кабинет») аша тапшырылырга мөмкин.<br>Шәхсән мөрәҗәгать иткәндә инвалид Россия Федерациясе гражданины паспортын яки аны алмаштыра торган документны; чит ил гражданинының, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документны күрсәтә | стандартның 5 пункты<br><br>518н номерлы федераль стандартның 6 пункты<br><br>518н номерлы федераль стандартның 13 пунктының 4 абзацы |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны | Халыкның мәшгульлек үзәге һәм МСЭ арасында ведомствоара үзара хезмәттәшлек каналлары аша ТАХП булган белешмәләр алына, алар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелгәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе турында» 2012 елның 7 августындагы 674 номерлы карары һәм 2015 елның 16 ноябрендәге 872н номерлы боерык белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелгәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе нигезендә ведомствоара электрон хезмәттәшлек итүнең бердәм системасыннан файдаланып, электрон формада | |

| | | |
|---|---|---|
| тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | тапшырыла.<br>Инвалид МСЭ тарафыннан бирелгән ТАХП үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы.<br>Инвалидтан түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте | Документларны кабул итүдән баш | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | тарту өчен нигезләр каралмаган | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | 210-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьясы<br>518н номерлы федераль стандартның 12 пункты |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Халыкның мәшгульлек үзәгенә беренче мәртәбә мөрәҗәгать иткән инвалид шәхсән мөрәҗәгать иткәндә дәүләт хезмәте чират тәртибендә күрсәтелә. Чират көтү вакыты 15 минуттан артып китәргә тиеш түгел.<br>Инвалидның мөрәҗәгать итү датасы һәм вакыты алдан килешенгән очракта дәүләт хезмәтен күрсәтүне көтү вакыты 5 минуттан артып китәргә тиеш түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь мөмкин булган вакыты – 60 минут. | 518н номерлы федераль стандартның 7 пункты<br><br>518н номерлы федераль стандартның 8 пункты<br>518н номерлы федераль стандартның 15 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүченең гаризасын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Инвалид шәхсән мөрәҗәгать иткәндә халыкның мәшгульлек үзәгенә килгән гариза халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан инвалид шәхсән мөрәҗәгать иткән көнне халыкның мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәте алучылар регистрын үз эченә алучы программа-техник комплексында (алга таба – ПК) теркәлә.<br>Инвалид тарафыннан гариза почта элемтәсе, факсимиль элемтә чараларыннан файдаланып җибәрелгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече аны килгән көнендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаларны теркәү журналында терки.<br>Инвалид тарафыннан гариза электрон формада, шул исәптән халыкның мәшгульлек үзәге рәсми сайты, Татарстан Республикасы порталы, | |

| | | |
|---|---|---|
| | Бердәм портал яки «Инвалидларның федераль реестры» системасында «шәхси кабинет» аша җибәрелгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече гаризаны кәгазьдә чыгартып ала һәм килгән көнендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү турында гаризаларны теркәү журналында терки.<br>Гариза электрон формада эшләми торган вакытта килгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече гаризаны килгән көненнән соң килүче беренче эш көнендә кәгазьгә чыгартып ала һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү турында гаризаларны теркәү журналында терки.<br>Гаризаны КФҮ тапшырган очракта, гариза вазыйфаи инструкция нигезендә гаризаны кабул итү һәм теркәүне гамәлгә ашыручы КФҮ хезмәткәре (алга таба – КФҮ хезмәткәре) тарафыннан килгән көнендә теркәлә.<br>КФҮ белән халыкның мәшгульлек үзәге арасында төзелгән хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән срокларда, ләкин гаризаны теркәгән көннән башлап киләсе эш көненнән соңга калмыйча, гаризаның халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшырылуы тәэмин ителә.<br>Гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә КФҮ килгән очракта, гариза ул КФҮ килгән көнне халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан ПК теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьләрне тутыру урыннарына, | Дәүләт хезмәтен күрсәтү бүлмәләре биналарның аерым керү юлы белән җиһазландырылган аскы катларында яки аерым торучы биналарда урнаша.<br>Хезмәт күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү) | |

| | | |
|---|---|---|
| аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның исемлеге урнаштырылган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәтне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларны урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр. Шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә дә. | мөмкинлеге тудырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урынына керү һәм чыгу өзлексез токның автоном чыганаклары белән тиешле күрсәткечләр белән җиһазландырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарда күренә торган җирдә янгын сүндерү чараларының урнашу һәм килүчеләрне һәм халыкның мәшгульлек үзәге белгечләрен эвакуацияләү юллары схемасы урнаштырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннар тавыш белән мәгълүмат җиткерү һәм электрон хәбәр итү системалары белән җиһазландырыла.<br>Хезмәт күрсәтү залларында (мәгълүмат залларында) гражданнарга туры килә торган эш вариантларын мөстәкыйль сайлау мөмкинлеген бирә торган белешмә-мәгълүмат һәм эзләтү системаларын үз эченә алган санау һәм электрон техника (алга таба – ПЭСМ) чаралары урнаштырыла. Белешмә-мәгълүмат һәм эзләтү системалары белән эшләү кагыйдәләре, шулай ук санау һәм электрон техника чаралары эше өчен җаваплы халыкның мәшгульлек үзәге белгеченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы һәм урнашу урыны турында белешмәләр ПЭСМ урнашкан урыннан турыдан-туры якын җирдә мәгълүмат стендында урнаштырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннар документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла, гариза бланклары, хезмәткәрләргә ихтыяҗ турында белешмә бланклары, таратыла торган мәгълүмат материаллары белән тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарда килүчеләргә файдалану мөмкинлеге булган иҗтимагый | |

| | | |
|---|---|---|
| | файдалану урыннарын (бәдрәфләрне) һәм өске кием-салымны саклау урыннарын җиһазлау күздә тотыла.<br>Халыкның мәшгульлек үзәге белгеченең эш урыны сигнализация чаралары (стационар «тревога төймәсе» яки күчмә күпфункцияле брелок-коммуникатор) белән җиһазландырыла, фамилиясен, исемен, атасының исемен һәм вазыйфасын күрсәтеп, стенага элеп куела торган элмә такта яки өстәл табличкасы белән тәэмин ителә.<br>Халыкның мәшгульлек үзәге белгече фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы күрсәтелгән шәхси күкрәк тамгасы (бейдж) белән тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен инвалидлар өчен халыкның мәшгульлек үзәкләрендә түбәндәгеләр тәэмин ителә:<br>халыкның мәшгульлек үзәгенә сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>зарурлык булганда инвалидлар өчен тавышлы мәгълүматны кабатлау, шул исәптән судротәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче ярдәмендә яки Брайльның рельефлы-нокталы шрифтыннан файдаланып. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт | Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең үтемлелек күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:<br>1. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү үрнәкләре турында | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 номерлы карары белән расланган тәртипнең 2.4 |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт | мәгълүматның инвалид өчен хосусый яки гавами (телдән яки язмача) мәгълүмат бирү формасында мөмкиндекле булуы (шәхсән кабул иткәндә, телефон элемтәсе, электрон почта чараларыннан файдаланып, массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару, мәгълүмат материаллары (брошюралар, белешмәлекләр, буклетлар һ.б.) нәшер итү, Татарстан Республикасы Порталында мәгълүмат урнаштыру юлы белән).<br>2. Инвалидка дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле гариза формаларын һәм башка документларны алу мөмкинлеген тәэмин итү, шул исәптән аларның күчермәләрен алу һәм электрон рәвештә тутыру мөмкинлеге белән.<br>3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтү вакытын саклау.<br>4. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән телефон элемтәсеннән, электрон почтадан файдаланып, Татарстан Республикасы порталы, КФҮ аша, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында.<br>5. Инвалидларга бүтән затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачау итүче киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә халыкның мәшгульлек үзәкләрендә халык мәшгульлеге турында Россия Федерациясе законнарындагымәҗбүри таләпләрнең, әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлүе.<br>2. Дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын | пункты |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтеннән файдалану мөмкинлеге (шул исәптән тулы күләмдә) яки файдалана алмау | саклау.<br>3. Әлеге Регламентта билгеләнгән административ процедураларның эзлеклелеген саклау.<br>4. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә баш тартуларның нигезле булуы.<br>5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләсе буенча нигезле шикаятьләрнең булмавы.<br>Инвалидның халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре белән үзара бәйләнешкә керү күләме:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар турыдан-туры тапшырылганда, – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>документларны почта аша җибәргәндә, шул исәптән электрон документ формасында, – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Үзара хезмәттәшлек итү озынлыгы әлеге Регламентта билгеләнә.<br>КФҮләрдә, КФҮләрнең читтәге эш урынында дәүләт хезмәте күрсәтелми.<br>Инвалид КФҮ, КФҮ читтән торып эшләү урынына мөрәҗәгать иткәндә, гариза теркәлгән көннән соңгы эш көненнән соңга калмыйча гаризаның халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшырылуы тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә халыкның мәшгульлек үзәге һәм КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – халыкның мәшгульлек үзәге һәм КФҮ арасында төзелә торган хезмәттәшлек турында килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлек итү тәртибе КФҮ эш регламенты белән җайга салына.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы гарызнамә составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | 518н номерлы федераль стандартның 17 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Дәүләт хезмәте электрон рәвештә күрсәтелми.<br>Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар халыкның мәшгульлек үзәгенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук гариза бирүче тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәгенә электрон саклагычлардан файдаланып та тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль законда һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш. | 518н номерлы федераль стандартның 17 пункты<br>63-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 11 пункты,<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясы, 6 пункты.<br>524н номерлы федераль стандарт»; |

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны (гамәлләрне) үз эченә ала:

инвалидны консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

документларны кабул итү һәм теркәү, инвалид турында халыкның мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы физик затлар регистрында булган инвалид турында белешмәләрне анализлау;

мәгълүматлар алу, ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул итү;

инвалидка дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү;

инвалидны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрү өчен халыкның мәшгульлек үзәге җаваплы белгечен билгеләү яки оешма сайлау;

инвалидны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрү өчен җаваплы булган халыкның мәшгульлек үзәге белгечен билгеләү турында боерык рәсмиләштерү, яисә инвалидка озата йөрү рәвешендә хосусый ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыручы дәүләткә карамаган оешма белән озата йөрү турында шартнамә төзү;

озата йөрү өчен билгеләнгән затлар (оешмалар) турында мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмәне рәсмиләштерү;

инвалидка бәяләмә бирү һәм аның шәхси эшенә бәяләмәнең икенче нөсхәсен теркәү;

административ процедуралар (гамәлләр) нәтиҗәләрен халыкның мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы физик затларның регистрына кертү;

халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта җибәрелгән техник хаталарны төзәтү.

3.2. Инвалидны консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

Процедураны башлап җибәрү өчен инвалидның шәхсән, телефон буенча, электрон почта һәм (яки) хат ярдәмендә дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итүе нигез булып тора.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече шәхсән, телефон аша, электрон почта һәм (яисә) хат аша, инвалидның мөрәҗәгать иткән ысулы нинди булуга карап, инвалидны, шул исәптән дәүләт хезмәтен алу өчен зарури булган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияли һәм инвалидка, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураны үтәү срогы инвалид мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураның нәтиҗәсе – консультация, тапшырылган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча кисәтүләр, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гаризаны төзү өлешендә.

3.3. Документларны кабул итү һәм теркәү, инвалид турында халыкның мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы физик затлар регистрында булган инвалид турында белешмәләрне анализлау.

3.3.1. Процедураны башлап җибәрү нигезе:

инвалидның халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән гариза белән мөрәҗәгать итүе;

инвалидның халыкның мәшгульлек үзәгенә, гаризаны почта элемтәсе ярдәмендә, факсимиль элемтә чараларыннан файдаланып яки электрон формада, шул исәптән халыкның мәшгульлек үзәге рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы Порталыннан, Бердәм порталдан файдаланып яки «Инвалидларның федераль реестры» системасындагы «шәхси кабинет», КФҮ аша җибәргән очракта, алдан ук аның белән килешенгән датада һәм вакытта мөрәҗәгать итүе.

Инвалид шәхсән мөрәҗәгать иткәндә мәшгульлек үзәгенә килгән гариза халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан инвалид шәхсән мөрәҗәгать иткән көнне халыкның мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәте алучылар регистрын үз эченә алган ПКда теркәлә.

Инвалид тарафыннан гариза электрон формада, шул исәптән халыкның мәшгульлек үзәге рәсми сайты, Татарстан Республикасы Порталы, Бердәм портал яки «Инвалидларның федераль реестры» системасында «шәхси кабинет» аша җибәрелгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече гаризаны кәгазьдә чыгартып ала һәм килгән көнендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү турында гаризаларны теркәү журналында терки.

Гариза электрон формада эшләми торган вакытта килгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече гаризаны килгән көненнән соң килә торган беренче эш көнендә кәгазьдә бастырып чыгара һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү турында гаризаларны теркәү журналында терки.

3.3.2. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

халыкның мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы физик затлар регистрына (алга таба – Физик затлар регистры) кертелгән инвалид турындагы белешмәләрне туры килә торган эшне эләү максатларында теркәлгән вакытта инвалид тапшырган түбәндәге документлар нигезендә анализлый: белеме турында һәм эш тәҗрибәсенең булуы, булган һөнәре (белгечлеге), алдагы хезмәт эшчәнлеге турында; һөнәри әзерлек һәм квалификация дәрәҗәсе, эш тәҗрибәсе һәм күнекмәләре турында; соңгы эш урыны буенча соңгы 3 айда исәпләнгән уртача хезмәт хакы турында; ТАХП булган, киңәш ителә торган хезмәт холкы һәм шартлары турында;

инвалидның ТАХП өземтәсендә булган, яшәешендә булган чикләмәләре, күрсәтелгән һәм күрсәтелмәгән хезмәт эшчәнлеге төрләре, хезмәт холкы һәм шартлары турында; һөнәри тернәкләндерү яки абилитацияләү буенча чаралар уздыру буенча киңәшләр турында һәм яңа эш сайлаганда һәм эшкә урнаштырганда, хосусый ярдәм күрсәтүне дә кертеп, аңа булышлык күрсәтү зарурлыгы турында таныклаучы башка белешмәләр турында турында мәгълүматларны өйрәнә;

ТАХП күрсәтелгән киңәшләргә ярашлы рәвештә туры килә торган эш вариантын сайлау максатында, вакансияләр базасына анализ уздыра.

Зарурлык булганда халыкның мәшгульлек үзәге белгече инвалидны эшкә урнаштыру буенча мөмкин булган тәкъдимнәрне сайлау өчен эш бирүчеләр белән кирәкле консультацияләрне үткәрә, эш бирүче белән дәүләт хезмәте күрсәтелә торган инвалид кандидатурасын килештерә.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече, инвалидны эшкә урнаштыру өчен вакансия (вакансияләр) сайлауны һәм аны (аларны) инвалид белән килештерүне гамәлгә ашырганнан соң, инвалидка тәкъдим ителә торган вакансияләрдә хезмәт холкын һәм шартларын анализлау нәтиҗәләре буенча эшкә урнашуда булышлык күрсәткәндә озата йөрүдә инвалидның мохтаҗ булуы турында МСЭ киңәшен алу максатларында, МСЭ белән мәгълүмати хезмәттәшлекне тәэмин итә.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураны үтәү срогы:

халыкның мәшгульлек үзәгенә инвалид шәхсән мөрәҗәгать иткән вакыттан башлап 5 минуттан артып китәргә тиеш түгел, әгәр инвалид ТАХП үз инициативасы белән тапшырган булса яки ТАХП халыкның мәшгульлек үзәгендә булган очракта;

Процедураның нәтиҗәсе: ТАХП күрсәтелгән киңәшләргә ярашлы рәвештә туры килә торган эш вариантын сайлау максатында, вакансияләр базасына анализ, эш бирүче белән консультация.

3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

3.4.1. Инвалид тарафыннан үз инициативасы белән МСЭ буенча федераль учреждениедән бирелгән ТАХП тапшырылмаган очракта һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә ТАХП өземтә булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 16 ноябрендәге 872н номерлы боерыгы нигезендә, халыкның мәшгульлек үзәге һәм МСЭ арасында белешмәләр алмашу кысаларында организмының бозылган функцияләрен һәм яшәешендәге чикләмәләрен исәпкә алып, инвалидның хезмәт һәм һөнәри эшчәнлеге буенча киңәш итела торган төрләрне сайлау өчен электрон формада белешмәләр (алга таба – ТАХП өземтә) ала.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураны үтәү срогы: гаризаны теркәгән көнне, инвалид үз инициативасы белән ТАХП тапшырмаган очракта яки халыкның мәшгульлек үзәгендә ТАХП өземтәсе булмаганда (МСЭ белән мәгълүмати хезмәттәшлек иткәндә).

Процедураларның нәтиҗәсе: ведомствоара электрон гарызнамә формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.2. Ведомствоара хезмәттәшлек органнары белгечләре шушы Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә соралган белешмәләрне (документларны) билгеләнгән чорда бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: рәсми мөрәҗәгатькә җавап нәтиҗәсе булган белешмәләр (документлар) яисә сорала торган белешмәләрнең булмавы турында халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрелгән хәбәр.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул итү.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече ТАХП өземтәсендә һәм гариза бирүчегә тәкъдим итела торган вакансияләрдә хезмәт холкына һәм шартларына анализ нәтиҗәләре буенча бирелгән эшкә урнашуда булышлык күрсәтелгәндә инвалидның озата йөрүгә мохтаҗ булуы турында МСЭ күрсәтмәсендә булган белешмәләр (инвалидның яшәешендә булган чикләмәләр турында, күрсәтелгән яки күрсәтелмәгән хезмәт эшчәнлеге төрләре, киңәш итела торган хезмәт шартлары турында) нигезендә инвалидка дәүләт ярдәме күрсәтү турында карар кабул итә.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураны үтәү срогы:

халыкның мәшгульлек үзәгенә инвалид шәхсән мөрәҗәгать иткән вакыттан башлап 10 минуттан артып китәргә тиеш түгел, әгәр инвалид ТАХП үз инициативасы белән тапшырган булса яки ТАХП халыкның мәшгульлек үзәгендә булган очракта;

гаризаны теркәгән датадан башлап 7 эш көне эчендә, инвалид үз инициативасы белән ТАХП тапшырмаган очракта яки халыкның мәшгульлек үзәгендә ТАХП өземтәсе булмаганда (МСЭ белән мәгълүмати хезмәттәшлек иткәндә).

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураның нәтиҗәсе булып дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул итү һәм ПК теркәү тора.

3.6. Инвалидка дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү.

Инвалидка дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча процедураны башлап җибәрү өчен халыкның мәшгульлек үзәге белгеченең инвалидка дәүләт хезмәте күрсәтү турында карары нигез булып тора.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килгәндә аңа түбәндәгеләр хакында мәгълүмат бирә:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә, вазыйфаи инструкция нигезендә инвалидларга эшкә урнашуда булышлык күрсәтүдә озата йөрү аларның вазыйфаи бурычларына керә торган халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре арасыннан халыкның мәшгульлек үзәге боерыгы нигезендә халыкның мәшгульлек үзәге белгече билгеләнәчәк яки аның белән шартнамә төзелгәннән соң озата йөрүне гамәлгә ашырачак оешма билгеләнәчәк;

инвалидны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрү өчен җаваплы булган халыкның мәшгульлек үзәге белгече билгеләнгәннән соң яки озата йөрүне гамәлгә ашыручы оешма белән шартнамә төзелгәннән соң халыкның мәшгульлек үзәге белгече дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә рәсмиләштерә, анда 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 25 нче кушымтага туры китерелгән форма буенча озата йөрү өчен билгеләнгән затлар (оешмалар) турында мәгълүмат була һәм аны инвалидка тапшыра.

Әгәр бу пунктта күрсәтелгән процедураны үтәү вакытында инвалид халыкның мәшгульлек үзәгенә килмәсә, инвалидка мәгълүмат җиткерү гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта аша яки электрон почта ярдәмендә электрон рәвештә, ТР Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетка) язмача гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураны үтәүнең максималь срогы инвалидка дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгән вакыттан башлап 3 минуттан артып китәргә тиеш түгел.

Процедураның нәтиҗәсе булып инвалидның халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килгәндә яки почта буенча яки электрон почта белән электрон рәвештә, ТР Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинеттан әлеге пунктта күрсәтелгән мәгълүматны алуы тора.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураның нәтиҗәсе халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан ПКда теркәлә.

3.7. Инвалидны эшкә урнаштырганда булышлык күрсәтеп озата йөрү өчен җаваплы булган халыкның мәшгульлек үзәге хезмәткәрен билгеләү яисә инвалидка озата йөрү рәвешендә хосусый ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыручы, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тиешле хезмәтләрне күрсәтергә

хокуклы булган дәүләткә карамаган оешманы, шул исәптән ихтыяри (волонтер) оешманы сайлау.

Процедураны башлап җибәрү өчен халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан инвалидка дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул итү һәм инвалидка дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат җиткерү нигез булып тора.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече вазыйфаи инструкция нигезендә инвалидларга эшкә урнашуда булышлык күрсәткәндә озата йөрү вазыйфаи бурычларына карый торган халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре арасыннан озата йөрү өчен җаваплы булган затны ачыклау өчен халыкның мәшгульлек үзәге белгече кандидатурасы турында тәкъдим (алга таба – озата йөрү өчен җаваплы кандидатура турында тәкъдим) рәсмиләштерә һәм аны килештерү өчен халыкның мәшгульлек үзәге директорына кертә.

Халыкның мәшгульлек үзәге директоры озата йөрү өчен җаваплы кандидатура турында тәкъдимне карый һәм аны килештерә. Халыкның мәшгульлек үзәге директоры озата йөрү өчен җаваплы кандидатура турында тәкъдимне кире каккан очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече озата йөрү өчен җаваплы кандидатура турында тәкъдимне кабат кертә.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү мөмкин булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече, озата йөрү турында шартнамә төзү максатында, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тиешле хезмәтләрне күрсәтүгә хокуклы булган оешмалар турында мәгълүмат җыя һәм анализлый.

Оешмалар турында мәгълүмат җыйганда һәм анализлаганда түбәндәгеләрне исәпкә ала:

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тиешле хезмәтне күрсәтү хокукының булуын;

инвалидларга эшкә урнашуда булышлык күрсәткәндә озата йөрү буенча гражданнарга оешма тарафыннан хезмәт күрсәтү тәртибен һәм шартларын;

инвалидларга ярдәм күрсәтү өчен әзерләнгән персоналның булуын.

Оешмалар турындагы мәгълүматларны анализлау нәтиҗәләре буенча халыкның мәшгульлек үзәге белгече озата йөрү турында шартнамә төзеп була торган оешманы сайлый һәм әлеге оешма белән шартнамә төзү турында тәкъдим рәсмиләштерә һәм аны килештерү өчен халыкның мәшгульлек үзәге директорына кертә.

Халыкның мәшгульлек үзәге директоры сайланган оешма турында тәкъдимне карый һәм аны килештерә. Халыкның мәшгульлек үзәге директоры оешма буенча тәкъдимне кире каккан очракта, башка оешманы сайлау буенча тәкъдимнәр кертү буенча гамәлләр кабат гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта каралган процедураны башкаруның максималь срогы халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан инвалидка дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгән һәм инвалидка дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат җиткерелгән вакыттан башлап 5 минуттан артып китәргә тиеш түгел.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураның нәтиҗәсе булып халыкның мәшгульлек үзәге директоры тарафыннан озата йөрү өчен җаваплы халыкның мәшгульлек үзәге белгече кандидатурасын килештерү, халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеге булмаганда озата йөрүне гамәлгә ашыручы оешманы билгеләү тора.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураның нәтиҗәсе халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан ПКда теркәлми.

3.8. Инвалидны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрү өчен җаваплы булган халыкның мәшгульлек үзәге белгечен билгеләү турында боерык рәсмиләштерү, яисә инвалидка озата йөрү рәвешендә хосусый ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыручы дәүләткә карамаган оешма белән озата йөрү турында шартнамә төзү.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураны башлау өчен нигез булып халыкның мәшгульлек үзәге директоры тарафыннан инвалидны озата йөрү өчен җаваплы белгеч кандидатурасын килештерү яки оешманы билгеләү тора.

3.8.1. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 24 нче кушымтага туры китерелгән форма буенча инвалидны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрү өчен җаваплы булган халыкның мәшгульлек үзәге белгечен билгеләү турында боерык рәсмиләштерә һәм имзалау өчен халыкның мәшгульлек үзәге директорына боерыкны тапшыра. Халыкның мәшгульлек үзәге директоры боерыкка кул куя һәм аны халыкның мәшгульлек үзәге белгеченә кайтарып бирә.

Инвалидны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрү өчен җаваплы булган халыкның мәшгульлек үзәге белгече боерык белән кул куеп таныша.

3.8.2. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан озата йөрү мөмкинлеге булмауга бәйле рәвештә оешма билгеләнгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече оешма тарафыннан озата йөрү турында шартнамә проектын әзерли.

Озата йөрү турында шартнамә проектын әзерләгәндә (телефон, факс, электрон почта аша яки оешма халыкның мәшгульлек үзәгенә килгән очракта, эш бирүченең шәхсән катнашында) оешма белән түбәндәгеләрне килештерә:

эш урынына бару һәм кайту юлын формалаштырганда һәм шул юлдан хәрәкәт итүне үзләштергәндә, инвалидка ярдәм күрсәтү тәртибен һәм шартларын;

шартнамәне үтәү барышы турында белешмәләр бирү тәртибен һәм срогына;

халыкның мәшгульлек үзәгенең һәм оешманың хокукларын, бурычларын һәм җаваплылыгын;

шартнамәнең гамәлдә булу срогын;

шартнамәне туктату тәртибен һәм шартларын.

Югарыда аталган килешү шартларын килештергәннән соң халыкның мәшгульлек үзәге белгече ике нөсхәдә оешма белән килешү проектын төзи һәм аларны кул кую өчен халыкның мәшгульлек үзәге директорына тапшыра. Халыкның

мәшгульлек үзәге директоры килешүне алган көнне аның ике нөсхәсенә кул куя һәм аларны халыкның мәшгульлек үзәге белгеченә тапшыра.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече килешүнең халыкның мәшгульлек үзәге директоры имзалаган ике нөсхәсен алганнан соң, имза кую өчен килешүнең ике нөсхәсен оешмага юллый.

Күрсәтелгән процедураларны үтәү вакыты:

әлеге Регламентның 3.8.1 пунктчасында күрсәтелгәнен, – әлеге Регламентның 3.7 пунктында каралган процедура тәмамланган вакыттан башлап 31 минуттан артык түгел.

әлеге Регламентның 3.8.3 пунктчасында, – әлеге Регламентның 3.7 пунктында каралган процедураны тәмамлаганнан соң 2 эш көненнән артык түгел.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураның нәтиҗәсе булып, инвалидны эш белән тәэмин иткәндә озата йөрү өченхалыкның мәшгульлек үзәгенең җаваплы белгечен билгеләү турында боерык яки халыкның мәшгульлек үзәге белән оешма арасында озата йөрү турында кул куелган килешү.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураның нәтиҗәсе халыкның мәшгульлек үзәге хезмәткәре тарафыннан ПКда теркәлә.

3.9. Озата йөрү өчен билгеләнгән затлар (оешмалар) турында мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмәне рәсмиләштерү.

Халыкның мәшгульлек үзәгенең инвалидны эш белән тәэмин иткәндә озата йөрү өчен җаваплы белгечен билгеләү яки оешма белән озата йөрү турында килешү процедураны башлау өчен нигез булып тора.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече электрон рәвештә 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка ярашлы форма буенча ике нөсхәдә бәяләмә төзи, аны бастырып чыгара, кул куя. Бәяләмәдә озата йөрүне гамәлгә ашыручы халыкның мәшгульлек үзәге белгече яки оешма турында мәгълүмат чагылдырыла.

Әлеге пунктта каралган процедураны башкаруның максималь срогы 5 минуттан артык булырга тиеш түгел.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураның нәтиҗәсе булып 2 нөсхәдә рәсмиләштерелгән бәяләмә тора.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураның нәтиҗәсе халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан ПКда теркәлә.

3.10. Инвалидка дәүләт хезмәтен күрсәтү турында бәяләмә бирү.

Процедураны башлап җибәрү өчен дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсмиләштерелгән бәяләмә нигез булып тора.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече бәяләмәне инвалидка дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән (халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә яки почта аша язмача, яки электрон почта белән, Татарстан Республикасы Порталында шәхси кабинетка) тапшыра.

Инвалид халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, халыкның мәшгульлек үзәге белгече инвалидны бәяләмәне белән кул куйдыртып таныштыра һәм инвалидка бәяләмәнең бер нөсхәсен бирә, икенче нөсхәсен инвалидның шәхси эшенә терки.

Әлеге пунктта каралган процедураны башкаруның максималь срогы 5 минуттан артык булырга тиеш түгел.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураның нәтиҗәсе булып инвалидка бер нөсхәдә бирелгән бәяләмә һәм инвалидның шәхси эшенә теркәлгән аның икенче нөсхәсе тора.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураның нәтиҗәсе халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан ПКда теркәлә.

3.11. Процедураларның нәтиҗәләрен халыкның мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы затлар – физик затлар регистрына кертү.

Процедураны башлап җибәрү өчен инвалидка бәяләмә бирү нигез булып тора. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече Физик затлар регистрына дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат кертә.

Әлеге пунктта каралган процедураны үтәүнең максималь срогы дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алган вакыттан башлап 1 минуттан артып китәргә тиеш түгел.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураның нәтиҗәсе халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан ПКда теркәлә.

3.12. Ттехник хаталарны төзәтү.

Процедураны башлап җибәрү өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә инвалидтан халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан бирелгән бәяләмәдә (алга таба – бирелгән документ) җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турында гариза килүе нигез булып тора.

Бирелгән документта җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү өчен инвалид язмача формада яки электрон документ формасында түбәндәгеләрне тапшыра:

әлеге Регламентның 5 нче кушымтасына туры китерелгән форма буенча бирелгән документта җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турында гариза (алга таба – хаталарны төзәтү турында гариза);

бирелгән документ.

Хаталарны төзәтү турында гариза инвалид тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәгенә яки КФҮ язмача рәвештә почта буенча яки электрон рәвештә электрон почта буенча, Татарстан Республикасы Порталы, Бердәм портал аша тапшырыла.

Язмача рәвештә хаталарны төзәтү турында гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә килгән көненнән башлап бер эш көне эчендә эш башкару өчен җаваплы булган халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан исәпкә алу журналында теркәлә. Язмача рәвештә хаталарны төзәтү турында инвалидтан эш сәгатьләрендә килмәгән гариза, килгән көненнән соңгы бернече эш көнендә теркәлә.

Хаталарны төзәтү турында гариза электрон рәвештә, шул исәптән Татарстан Республикасы Порталы аша килгән очракта, эш башкару өчен җаваплы халыкның мәшгульлек үзәге белгече хаталарны төзәтү турында гаризаны бер эш көне дәвамында кәгазьгә чыгартып ала һәм алга таба аның белән язма рәвештә хаталарны төзәтү турында гариза белән эшләүгә аналогик эш алып бара.

Хаталарны төзәтү турында гариза һәм элегрәк бирелгән документ хаталарны төзәтү турында гариза халыкның мәшгульлек үзәгендә теркәлгән көнне эш башкару өчен җаваплы халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәге директорына тапшырыла.

Халыкның мәшгульлек үзәге директоры хаталарны төзәтү турында гариза халыкның мәшгульлек үзәгендә теркәлгән датадан башлап 1 эш көне эчендә хаталарны төзәтү турында гаризаны карый, яңа документ бирү юлы белән бирелгән документтагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турында як бирелгән документтагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарту турында карар кабул итә, дәүләт хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыручы халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре арасыннан башкаручыны (алга таба – башкаручы) билгели һәм аңа язмача тиешле йөкләмә бирә.

Бирелгән документта хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарту турында карар бирелгән документта хаталарның һәм ялгышларның булмау факты билгеләнгән очракта кабул ителә.

Бирелгән документта хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турында карар кабул ителгән очракта, башкаручы халыкның мәшгульлек үзәгендә хаталарны төзәтү турында гариза теркәлгән көннән башлап 3 эш көне эчендә бирелгән, хаталары һәм ялгышлары булган документка алмашка яңа документ (алга таба – яңа документ) әзерли һәм яңа документны эш башкару өчен җаваплы халыкның мәшгульлек үзәге белгеченә тапшыра.

Хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, башкаручы халыкның мәшгульлек үзәгендә хаталарны төзәтү турында гариза теркәлгән көннән башлап 3 эш көне эчендә бирелгән документта хаталарның һәм ялгышларның булмавы турында хәбәр проекты (алга таба - хаталарның булмавы турында хәбәр) әзерли һәм аны кул кую өчен халыкның мәшгульлек үзәге директорына тапшыра.

Хаталарның булмавы турында хәбәр проектына элек бирелгән документ теркәлә.

Хаталарның булмавы турында хәбәр проекты имза салу өчен килгән көненнән башлап бер эш көне эчендә халыкның мәшгульлек үзәге директоры тарафыннан имзалана һәм аның тарафыннан эш башкару өчен җаваплы халыкның мәшгульлек үзәге белгеченә шул ук көнне тапшырыла.

Эш башкару өчен җаваплы халыкның мәшгульлек үзәге белгече халыкның мәшгульлек үзәге директоры хаталарның булмавы турында хәбәргә кул куйган яки яңа документны алган көннән башлап бер эш көне эчендә хаталарның булмавы турында хәбәрне яки яңа документны тиешле документларны исәпкә алу журналында терки.

Эш башкару өчен җаваплы халыкның мәшгульлек үзәге белгече яңа документны яки хаталарның булмавы турында хәбәрне теркәгән көнне инвалидка яңа документның әзер булуы яки хаталарның булмавы турында турында хаталарны төзәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән хәбәр итә.

Хаталарның булмавы турында хәбәрне теркәгән яки яңа документны алган көннән соң килүче бер эш көне узганчы эш башкару өчен җаваплы халыкның мәшгульлек үзәге белгече инвалидка хаталарны төзәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән яңа документ яки хаталарның булмавы турында хәбәр бирә.

Хаталарның булмавы турында хәбәр хаталарны төзәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән, элегрәк бирелгән документ белән бергә бирелә.

Әлеге пунктта каралган процедураны башкаруның максималь срогы хаталарны төзәтү турында гариза халыкның мәшгульлек үзәгендә теркәлгән көннән башлап биш эш көненнән артып китәргә тиеш түгел.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураның нәтиҗәсе булып гариза бирүчегә яңа документны яки хаталарның булмавы турында хәбәр тапшыру тора.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедура нәтиҗәсен теркәү ысуллары булып тиешле исәпкә алу документациясе журналында яңа документны яки хаталарның булмавы турында хәбәрне теркәү, шулай ук яңа документны яки хаталарның булмавы турында хәбәрне шәхсән алганда инвалидның кул куюы тора»;

4 бүлектә түбәндәге эчтәлекле $4.5^1$ пункт өстәргә:

«$4.5^1$. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;

5 бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

боерыкның 5.1 пунктындагы өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

Регламентка түбәндәге эчтәлекле 6 бүлек өстәргә:

«6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

6.1. Гариза бирүче КФҮ мөрәҗәгать иткәндә, гамәлләр тәртибен тасвирлау.

КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында гариза бирүчегә хәбәр итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

халыкның мәшгульлек үзәгенә документлар белән гариза җибәрү;

6.2. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү.

Гариза бирүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен КФҮ шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ белгече гариза бирүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны КФҮнең http://mfc16.tatarstan.ru сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе булып, тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдаланучы затның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат җиткерү тора.

6.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

6.3.1. Гариза бирүче шәхсән яисә ышанычлы заты аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза тапшыра һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә КФҮ, КФҮнең читтән торып эшләү урынына тапшыра.

6.3.2. КФҮнең гаризалар кабул итә торган белгече КФҮнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар КФҮнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.4. Халыкның мәшгульлек үзәгенә гаризаны җибәрү.

6.4.2. КФҮ белгече гаризаны халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә халыкның мәшгульлек үзәге һәм КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – халыкның мәшгульлек үзәге һәм КФҮ арасында төзелә торган хезмәттәшлек турында килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлек итү тәртибе КФҮ эш регламенты белән җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар КФҮнең эш регламентында, халыкның мәшгульлек үзәге белән КФҮ арасындагы үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны КФҮдә теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – халыкның мәшгульлек үзәгенә юлланган гариза.

6.5. Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү.

6.5.1. Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан бирелгән бәяләмәдә хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турындагы гаризаны гариза бирүче шәхсән яки ышанычлы заты аша КФҮгә язмача тапшыра.

КФҮнең гаризалар кабул итә торган белгече КФҮнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар КФҮнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – техник хаталарны

төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.6. Халыкның мәшгульлек үзәгенә техник хаталарны төзәтү турында гариза җибәрү.

6.6.2. КФҮ белгече халыкның мәшгульлек үзәге һәм КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, әмма гаризаны КФҮдә теркәгән көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрә.»;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Инвалидларга эшкә урнашуда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

1. Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре

| т/с | Халыкның мәшгульлек үзәгенең аталышы | Вазыйфа | Телефон | Урнашкан урын адресы, электрон адресы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | «Азнакай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85592) 7-57-90 | 423330, Азнакай шәһәре, Төзүчеләр урамы, 10 Czn.Aznakaevo@tatar.ru |
| 2 | «Аксубай районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84344) 2-73-94 | 423060, Аксубай ш.т.п., Романов урамы, 6 Czn.Aksubaevo@tatar.ru |
| 3 | «Актаныш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-85552) 3-09-83 | 423740, Актаныш районы, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 61 Czn.Aktanysh@tatar.ru |
| 4 | «Алексеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84341) 2-54-00 | 422900, Алексеевск эшчеләр поселогы, Ленин урамы, 87 Czn.Alekseevskoe@tatar.ru |
| 5 | «Әлки районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт | директор | (84346) 2-15-89 | 422870, Базарлы Матак авылы, Совет урамы, 8 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | казна учреждениесе | | | Czn.Alkeevo@tatar.ru |
| 6 | «Әлмәт шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8553) 32-45-47 | 423452, Әлмәт шәһәре, Герцен урамы, 86а Czn.Almet@tatar.ru |
| 7 | «Апас районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84376) 2-12-15 | 422350, Апас авылы, Шоссейная урамы, 5 Czn.Apastovo@tatar.ru |
| 8 | «Арча районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84366) 3-17-33 | 422000, Арча ш.т.п., Банк урамы, 6в Centr.Arskiy@tatar.ru |
| 9 | «Әтнә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84369) 2-16-51 | 422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы, 63 Czn.Atnya@tatar.ru |
| 10 | «Баулы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85569) 5-62-29 | 423930, Баулы шәһәре, Энгельс урамы, 56 Czn.Bavly@tatar.ru |
| 11 | «Балтач районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84368) 2-44-19 | 422250, Балтач ш.т.п., Совет урамы, 16 Czn.Baltasi@tatar.ru |
| 12 | «Бөгелмә шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85594) 4-17-60 | 423230, Бөгелмә шәһәре, Октябрь урамы, 15 Czn.Bugulma@tatar.ru |
| 13 | «Буа шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84374) 3-13-73 | 422430, Буа шәһәре, Р.Люксембург урамы, 157/1 Czn.Buinsk@tatar.ru |
| 14 | «Югары Ослан районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-84379) 2-24-28 | 422570, Югары Ослан районы, Югары Ослан авылы, Медгородок урамы, 21 а Czn.V-uslon@tatar.ru |
| 15 | «Биектау районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84365) 2-16-17 | 422700, Биектау авылы, Центральная урамы, 7 CZN.VGora@tatar.ru |
| 16 | «Чүпрәле районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт | директор | (8-84375) 2-24-51 | 422470, Иске Чүпрәле авылы, Центральная |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | казна учреждениесе | | | урамы, 15<br>Czn.Drozhzhanoe@tatar.ru |
| 17 | «Алабуга шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85557)<br>7-58-58 | 423600, Алабуга шәһәре, Спас урамы, 5<br>Czn.Elabugi@tatar.ru |
| 18 | «Зәй шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85558)<br>7-15-43 | 423520, Зәй шәһәре, Нефтьчеләр проспекты, 37б<br>Czn.Zainsk@tatar.ru |
| 19 | «Зеленодольск шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84371)<br>5-64-90 | 422550, Зеленодольск шәһәре,<br>Татарстан урамы, 1<br>Czn.Zdol@tatar.ru |
| 20 | «Кайбыч районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84370)<br>2-12-60 | 422330, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7<br>Czn.Kaibicy@tatar.ru |
| 21 | «Кукмара районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84364)<br>2-67-54 | 422110, Кукмара шәһәре, Ворошилов урамы, 44<br>Czn.Kukmor@tatar.ru |
| 22 | «Лаеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-84378)<br>2-44-54 | 422610, Лаеш шәһәре, Чернышевский урамы, 23<br>Laish.Czn@tatar.ru |
| 23 | «Лениногорск шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85595)<br>5-59-70 | 423250, Лениногорск шәһәре, Гагарин<br>урамы, 51<br>Czn.Leninogorsk@tatar.ru |
| 24 | «Мамадыш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-85563)<br>3-35-57 | 422190, Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы, 12<br>Czn.Mamadysh@tatar.ru |
| 25 | «Менделеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Менделеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Әгерже | директор | (85549)<br>2-23-57<br><br>(85551)<br>2-31-73 | 423650, Менделеевск шәһәре, Фомин<br>урамы, 19<br>Czn.Men@tatar.ru;<br>422230, Әгерже шәһәре, К.Маркс урамы, 11а<br>Centr.Agryzskiy@tatar.ru |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | районы филиалы | | | |
| 26 | «Минзәлә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-85555) 3-23-80 | 423700, Минзәлә шәһәре, Ленин урамы, 80 Czn.Menzelinsk@tatar.ru |
| 27 | «Мөслим районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85556) 2-57-37 | 423970, Мөслим авылы, Пушкин урамы, 47 Czn.Muslymovo@tatar.ru |
| 28 | «Яр Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Яр Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Тукай районы филиалы | директор | (8552) 52-42-68<br><br>(8552) 52-96-97 | 423831, Яр Чаллы шәһәре, Сөембикә проспекты, 47 Chelny.CZN@tatar.ru; 423831, Яр Чаллы шәһәре, Сөембикә проспекты, 47 Czn.Tukaev@tatar.ru |
| 29 | «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Кама Аланы бүлеге | директор | (8555) 42-40-79 (8555) 33-98-61 | 423570, Түбән Кама шәһәре, Бызов урамы, 20а Czn.Nk@tatar.ru 423564, Түбән Кама районы, Кама Аланы эшчеләр поселогы, 2/01 Czn.Nk@tatar.ru |
| 30 | «Яңа Чишмә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-84348) 2-23-43 | 423190, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Ленин урамы, 93 Czn.Novoshesh@tatar.ru |
| 31 | «Нурлат ш. халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84345) 2-46-30 | 423040, Нурлат шәһәре, Р.С.Хәммәдиев урамы, 19 Czn.Nurlat@tatar.ru |
| 32 | «Питрәч районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84367) 3-04-84 | 422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 34 CentrZan.Pestr@tatar.ru |
| 33 | «Балык Бистәсе районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84361) 2-21-81 | 422650, Балык Бистәсе ш.т.п., Ленин урамы, 48 Czn.R.sloboda@tatar.ru |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 34 | «Саба районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-84362) 2-28-15 | 422060, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., З.Йосыпов урамы, 7 SZN.Saby@tatar.ru |
| 35 | «Сарман районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85559) 2-42-62 | 423350, Сарман авылы, Ленин урамы, 26 Czn.Sarmanovo@tatar.ru |
| 36 | «Спас районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84347) 3-07-72 | 422820, Болгар шәһәре, Хирург Шеронов урамы, 21 Czn.Bolgar@tatar.ru |
| 37 | «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Кама Тамагы районы филиалы | директор | (84373) 2-63-29<br><br>(8-84377) 2-14-67 | 422370, Тәтеш шәһәре, Ирек мәйданы урамы, 45 Czn.Tetyushi@tatar.ru; 422820, Кама Тамагы районы, Кама Тамагы ш.т.п., К. Маркс урамы, 2а Filial.K-uste@tatar.ru |
| 38 | «Теләче районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84360) 2-13-51 | 422080, Теләче авылы, Ленин урамы, 73 Czn.Tyulyachi@tatar.ru |
| 39 | «Чирмешән районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84396) 2-54-59 | 423100, Чирмешән авылы, Титов урамы, 5 Czn.Cheremshan@tatar.ru |
| 40 | «Чистай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84342) 5-13-34 | 422980, Чистай шәһәре, К.Маркс урамы, 35 Czn.chist@tatar.ru |
| 41 | «Ютазы районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-85593) 2-60-18 | 423950, Урыссу ш.т.п., Пушкин урамы, 105/1 Czn.Yutazy@tatar.ru |
| 42 | «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең | директор | (843) 562-48-33 (843) 273-85-03 | 420034, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 81а Czn.g_Kazan@tatar.ru; 420029, Казан шәһәре, Журналистлар урамы, 13а CZN/Sovetskiy@tatar.ru |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Совет районы филиалы | | | |
| 43 | «Авиатөзелеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 537-86-00 | 420085, Казан шәһәре, 1 нче Муром урамы, 33а Czn.Avia@tatar.ru |
| 44 | «Вахитов районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 277-51-59 | 420049, Казан шәһәре, Качалов урамы, 77 Czn.Vah@tatar.ru |
| 45 | «Киров районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 554-77-36 | 420032, Казан шәһәре, Слободская урамы, 23 czn.kirovskiy@tatar.ru |
| 46 | «Мәскәү районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 543-47-72 | 420039, Казан шәһәре, Гагарин урамы, 46 czn.moskovski@tatar.ru |
| 47 | «Яңа Савин районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 543-19-52 | 420044, Казан шәһәре, Ибраһимов проспекты, 41 Czn.Novosavin@tatar.ru |
| 48 | «Идел буе районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 224-86-83 | 420101, Казан шәһәре, Бертуган Касыймовлар урамы, 22/7 CZN.Privol@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-03 | Klara.Tazetdinova@tatar.ru |
| Социаль яклнмаган категорияләр өчен эш урыннары булдыру бүлеге башлыгы | 557-20-73 | Elena.Kibardina@tatar.ru»; |

Регламентка 2 нче кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга.